ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 08 » апрель 2022 ел № 252

**«2022 елга Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмалары тарафыннан халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» Арча районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1654 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1654 номерлы карарына карата Арча районы прокуратурасының 2022 елның 29 мартындагы 02-08-02/2022 номерлы дәгъвасы нигезендә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга яраклаштырып, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2022 елга Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмалары тарафыннан халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» Арча районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1654 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Татмедиа» ААҖ филиалы «Арча хәбәрләре» («Арский вестник») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталына (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Ә.Кадыйровка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*«08» апрель 2022 ел, №252*
*карарына 1 нче кушымта*

**2022 елга торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милечеләре һәм торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга (алга таба – халыкка торак хезмәтләре)**

**ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| № | Түләү исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | 2022 елның I яртыеллыгына хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) | 2022 елның II яртыеллыгына хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 3,60 | 3,75 |
| 2. | Ишегалдын карап тоту (шул исәптән чүп контейнерларын) | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 3,40 | 3,97 |
| 3. | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 2,25 | 2,35 |
| 4. | Торак биналарга агымдагы ремонт ясау | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 3,50 | 3,65 |
| 5. | Дератизация (дезинсекция) | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,23 | 0,31 |
| 6. | Йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,18 | 0,19 |
| 7. | Йорт эчендәге электр челтәрләренә агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,50 | 0,55 |
| 8. | Йорт эчендәге үзәк җылыту системасына агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,11 | 0,11 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә (югары насос станцияләре белән җиһазландырылмаган су белән тәэмин итү һәм канализация челтәрләре) агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 1,75 | 1,80 |
| 10. | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә (югары насос станцияләре белән җиһазландырылган су белән тәэмин итү һәм канализация челтәрләре) агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 2,25 | 2,35 |
| 11. | Домофон | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,96 | 1,00 |
| 12. | Төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,80 | 0,85 |
| 13. | Җилләтү юлларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,80 | 0,85 |
| 14. | Телевидениене күмәк кабул итү системаларын техник яктан тәэмин итү һәм ремонтлау | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | - | 0,43 |

Башкарма комитетның инфраструктура
үсеше бүлегенең ТКХ, энергетика
һәм элемтә секторы мөдире А.Р.Шәйхетдинов